# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**Дүртенче чакырылыш унынчы утырыш**

**15 ноябрь 2021 ел № 41 Олы Мәтәскә авылы**

Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2015 елның 16.06.2015 №138 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2015 елның 16.06.2015 №138 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.»;

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча регламентка:

ә) 3.4 пунктны түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«3.4. Җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә гражданин үз фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне яңадан үзгәртү турында хәбәр җибәрелергә тиешле электрон почта адресын мәҗбүри рәвештә күрсәтә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада теркәргә хокуклы.»;

б) IV бүлекне түбәндәге эчтәлекле 4.2.1 пункты белән тулыландырырга:

«4.2.1. Язма мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул үз компетенцияләре нигезендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка карауга юлланмый, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга хәбәр ителә.»;

в) 6.1 пунктының 5 абзацын төшереп калдырырга;

г) 6.1 пунктының 8 абзацын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«6.1. "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында күрсәтелгән очраклардан тыш, мөрәҗәгать итеп куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап алырга, ә "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 5.1 өлешендә каралган очракта, аны бирү турындагы үтенеч белән мөрәҗәгать итү нигезендә, язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү

компетенциясенә кергән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язмача мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә нигезендә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Авыл җирлеге башлыгы М. А. Валиуллин